РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422054, Республика Татарстан, Сабинский район,с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.06.2021

КАРАР
№16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
25.02.2021 ел, 6нчы номерлы карары белән расланган
Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә
һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге
җирләргә Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә
яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 27.05.20021 нче елгы таләбе нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 25.02.2021 елда «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләрдә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 6нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләрдә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Нигезләмәнең 3.14 пунктында «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен“рехсәт ителә»сүзләре белән алмаштырырга;

Нигезләмәнең 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3.8. Авыл башкарма комитеты мерәҗәгать итүченең хат-гаризасы, яшел үсентеләрне техник тикшерү акты, киселгән агач ечен түләүне исәпләгәннән соң 10 эш кене эчендә авыл җирлеге башкарма комитетының авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләр кисүгә рөхсәт бирү турындагы карары проектын әзерли.»;

Нигезләмәнең 3.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә белән тулыландырырга: «киселгән агач өчен бәя (түләү) исәпләү. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 22.05.2007 ел, №310 карары белән расланган «Урман ресурслары күләме берәмлегe ечен түләү ставкалары һәм Федераль милектә булган урман

кишәрлеге мәйданы бирәмлеге өчен түләү ставкалары турында» карары нигезендә исәпләнә.»

1. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча, җирлекнең мәгълумати стендларында бастырып чыгарырга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз кечена керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов